# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегең Кече Чура авылында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

24 ноябрь 2025 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Кече Чура авылында гражданнар җыены карар чыгарды:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Кукмара районы Югары Чура авыл җирлегенең Кече Чура авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;
- урамнарны яктырту җайланмасы;
- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- коеларны төзекләндерү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;
- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;
- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту;
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;
- янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын төзү, ремонтлау;

- мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр)булмага һәйкәлләрне төзү, ремонтлау

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомоби юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- тротуарларны төзү, ремонтлау;

- тукталыш комплексларын ремонтлау, сатып алу һәм урнаштыру;

торак пункт чикләрендә җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, гомум файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юллары составына керми торга җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау;

- ремонт, коймалар кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү;

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуна калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү.

3. Әлеге карарны Югары Чура авыл җирлегенең мәгълүмат стендларын Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы http://pravo.tatarstan һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре портал составындагы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында kukmor.tatarstan. урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукы актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Чура авыл җирлеге
Башлыгы урынбасары: Афанасьев А.Н